КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 март г.Казань № 109

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 207 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 13 май, 313 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә җирле үзидарә органнары структурасын билгеләгәндә әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартына таянып эш итүне тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 ел, 5 март, 178 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 август, 559 нчы; 2018 ел, 6 декабрь, 1084 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне

исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентына, I бүлекнең 1.4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.4. Дәүләт хакимияте башкарма органына һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә функциональ анализ бер үк вакытта өч елга бер тапкыр үткәрелә. Дәүләт хакимияте башкарма органын төзегән йә аны үзгәртеп оештырган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының яңа структур бүлекчәсен керткән (төшереп калдырган) очракта, функциональ анализлау процедурасы, әлеге процедуралар тәмамлангач, бер елдан соң үткәрелә.».

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен (хезмәтләрен) башкаруга (күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибен һәм дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 17 июль, 500 нче; 2018 ел, 14 август, 666 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен (хезмәтләрен) башкаруга (күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибенең 3.1 нче пунктындагы җиденче абзацында «11,5» саннарын «19,4» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасында:

4.1 пунктның 2 нче таблицасында «Бухгалтерия исәбе» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Бухгалтерлык исәбе | хезмәткәрләр саны | 100 хезмәткәргә 1 ставка | + | |
| | | 1 баш бухгалтер ставкасы | + | |
| | | физик һәм юридик затлар белән 1 000 подряд шартнамәсенә 1 бухгалтер ставкасы | +»; | |

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең гомуми норматив санын исәпләп чыгарганда дәүләт учреждениесе җитәкчесе һәм аның урынбасарлары исәпкә алына.

Дәүләт учреждениесе җитәкчесенең вазыйфасы «директор» дип атала. Дәүләт учреждениесе җитәкчесенең иң күбе бер ярдәмчесе булырга мөмкин. Оештыру структурасында һәм штат расписаниесендә киңәшче вазыйфасы булу рөхсәт ителми.

Дәүләт учреждениесе җитәкчесе урынбасарларының саны дәүләт учреждениесен гамәлгә куючы карары белән раслана.

Дәүләт учреждениесе җитәкчесе урынбасарының үз буйсынуында кимендә өч структур бүлекчәсе булырга тиеш.

Дәүләт учреждениесе җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары саны хезмәткәрләрнең гомуми штат санының 30 процентыннан артмаска тиеш.

Гамәлгә куючы карары буенча дәүләт учреждениесенең оештыру структурасы, законнарда каралган очраклардан тыш, дәүләт учреждениесе җитәкчесе яисә аны гамәлгә куючы боерыгы белән төзелергә һәм расланырга мөмкин.

Дәүләт учреждениесенең оештыру структурасына дәүләт учреждениесе эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча төзелгән департаментлар, идарәләр, бүлекләр, секторлар формасында, шулай ук дәүләт учреждениесе эшчәнлеген оештыру, матди-техник һәм башка тәэмин итү максатларында структур бүлекчәләр керергә мөмкин.

Департамент составында кимендә өч структур бүлекчә булырга тиеш, аның составында кимендә бер идарә һәм бер бүлек булуы мәҗбүри булып тора.

Идарә структурасына гомуми штат саны кимендә 13 берәмлек булган кимендә өч структур бүлекчә керергә тиеш. Әгәр дә идарәнең штат саны 13 берәмлектән артык (шул исәптән идарә башлыгын кертеп) тәшкил итсә, идарәдә идарә башлыгы урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Идарә башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы штат саны 26 берәмлек һәм аннан күбрәк (идарә башлыгын кертеп) булганда кертелергә мөмкин.

Бүлекләрнең штат саны кимендә дүрт берәмлек булырга тиеш.

Хокукый, кадрлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы бүлекләр формасында, мобилизация эше буенча структур бүлекчәләрдә штат саны кимендә өч берәмлек булырга тиеш. Әлеге бүлекчәләрдә штат саны ике берәмлек булган очракта, алар сектор формасында оештырыла.

Бүлек башлыгы урынбасары вазыйфасы бүлекнең штат саны кимендә алты берәмлек (шул исәптән бүлек башлыгын кертеп) булганда кертелә.

Бүлек башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы бүлекнең штат саны кимендә 12 берәмлек (шул исәптән бүлек башлыгын кертеп) булганда кертелә.

Секторларда штат саны ике яки өч берәмлек булырга яисә департаментлар, идарәләр, бүлекләр составына керергә, яисә аның мөстәкыйль структур бүлекчәләре булырга мөмкин.

Дәүләт учреждениесенең оештыру структурасында хокукый, кадрлар белән тәэмин итү, мобилизация эше буенча аерым белгечләр, шулай ук матбугат сәркатибе сыйфатында белгеч булу рөхсәт ителә.

Хокукый, кадрлар белән тәэмин итүне, бухгалтерлык исәбен, мобилизация эшен алып баруны гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр (бүлекләр, секторлар, аерым белгечләр) һәм матбугат сәркатибе дәүләт учреждениесе җитәкчесенең турыдан-туры буйсынуында булырга тиеш.

Дәүләт учреждениесенең штат расписаниесендә дәүләт учреждениесен матди, техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү мәсьәләләренә җавап бирүче эшләр идарәчесе вазыйфасы булу рөхсәт ителә. Эшләр идарәчесенең хезмәт өчен түләү дәрәҗәсе дәүләт учреждениесенең расланган хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә идарә башлыгының хезмәт өчен түләү дәрәҗәсенә туры килә. Аның тарафыннан җавап бирелә торган структур бүлекчәләр саны дәүләт учреждениесенең оештыру структурасы белән билгеләнә.

Дәүләт учреждениесенең хезмәт күрсәтүче персоналы вазыйфалары («машина йөртүче» вазыйфасын кертеп) (балансда булган яки арендага алына торган хезмәт урынында кулланылган автотранспорт булганда) штат расписаниесенә кертелә, яки әлеге персонал функцияләре законнар нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә, дәүләт учреждениесендә үзәк аппаратның хезмәт күрсәтүче персоналының штат санын алга таба кыскартып, башка оешмага тапшырыла. Хезмәт күрсәтүче персоналның норматив штат саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән нормативлардан чыгып билгеләнә.».

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә 2021 елның 1 апреленә кадәр үзләренең оештыру структураларын бу карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 7 апрель, 207 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 март, 109 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте
башкарма органының үзәк аппараты структурасы
стандарты

1. Әлеге Стандарт Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында (алга таба – дәүләт хакимияте башкарма органы) үзәк аппаратының оештыру структурасына карата таләпләрне билгели (алга таба – дәүләт хакимияте башкарма органы).

2. Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның оештыру структурасы, законнар белән каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

3. Дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппаратында дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарлары, шулай ук структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һәм аларның урынбасарлары саны дәүләт хакимияте башкарма органындагы үзәк аппарат хезмәткәрләренең гомуми штат санының 30 процентыннан артмаска тиеш. Төп киңәшчеләр саны дәүләт хакимияте башкарма органындагы үзәк аппарат хезмәткәрләренең гомуми штат санының 20 процентыннан артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренә кертелгән дәүләт хезмәткәрләре саны дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппаратында барлык вазыйфалар төркемнәрендәге дәүләт хезмәткәрләренең гомуми санынннан кимендә 10 процент тәшкил итәргә тиеш.

4. Дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарлары саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә. Дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасында (үзәк аппарат структурасында иң күбе ике беренче урынбасарлары булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгыннан тыш) бер беренче урынбасардан артык була алмый.

Дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесенең беренче урынбасары ведомство буйсынуындагы эшчәнлек өлкәсен, тулаем алганда, һәм дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлегенең төп юнәлешләрен үстерү өчен җавап бирергә тиеш. Дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарлары беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җавап бирә.

5. Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 40 берәмлеккә кадәр булганда, дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарының үз буйсынуында, бүлекчә хезмәткәрләренең гомуми штат саны кимендә алты берәмлек тәшкил иткәндә, кимендә ике структур бүлекчәсе булырга тиеш.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 41 берәмлектән 100 берәмлеккә кадәр булганда, дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарының үз буйсынуында, бүлекчә хезмәткәрләренең гомуми штат саны кимендә сигез берәмлек тәшкил иткәндә, кимендә ике структур бүлекчәсе булырга тиеш.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 100 берәмлектән артык булганда, дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарының үз буйсынуында, бүлекчә хезмәткәрләренең гомуми штат саны кимендә 12 берәмлек тәшкил иткәндә, кимендә өч структур бүлекчәсе булырга тиеш.

6. Министр урынбасары буйсынуында департамент яки идарә формасында бер бүлекчә булырга мөмкин. Шул ук вакытта аның вазыйфасы «министр урынбасары – Татарстан Республикасы министрлыгының идарә (департамент) башлыгы» дип атала.

7. Министрлыклар һәм дәүләт комитетлары җитәкчеләренең иң күбе бер ярдәмчесе булырга мөмкин. Татарстан Республикасы ведомстволары җитәкчеләренең ярдәмчесе була алмый.

Дәүләт хакимияте башкарма органының оештыру структурасында матбугат сәркатибе сыйфатында аерым белгеч булуы рөхсәт ителә.

Дәүләт хакимияте башкарма органының штат санында 40 берәмлектән кимрәк булса, аның оештыру структурасында хокукый, кадрлар белән тәэмин итү, мобилизация эше буенча аерым белгечләрнең штат саны булуы рөхсәт ителә.

Хокукый, кадрлар белән тәэмин итү, мобилизация эше буенча аерым белгечләрнең һәм матбугат сәркатибенең хезмәте өчен түләү дәрәҗәсе дәүләт хакимияте башкарма органының расланган хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә бүлек башлыгының хезмәте өчен түләү дәрәҗәсенә туры килә.

8. Министрлыкларның һәм дәүләт комитетларының штат расписаниесендә эшләр идарәчесе вазыйфасы каралырга мөмкин. Эшләр идарәчесе дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеген оештыру, матди-техник һәм башка тәэмин итү өчен җавап бирә. Эшләр идарәчесенең хезмәте өчен түләү дәрәҗәсе дәүләт хакимияте башкарма органының расланган хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә идарә башлыгының хезмәте өчен түләү дәрәҗәсенә туры килә. Эшләр идарәчесе хезмәт күрсәтүче бүлекчәләр эшчәнлеген координацияли, аларның саны дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның оештыру структурасы белән билгеләнә.

9. Дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасына департаментлар, идарәләр, бүлекләр һәм башка структур бүлекчәләр керергә мөмкин.

10. Департамент составында кимендә бер идарәнең һәм бер бүлекнең мәҗбүри булу шарты белән кимендә өч структур бүлекчә булырга тиеш.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 40 берәмлеккә кадәр (40 берәмлекне кертеп) булганда департамент хезмәткәрләренең штат саны кимендә 14 берәмлек тәшкил итә. Департаментта, әгәр дә департаментның штат саны 14 берәмлектән (департамент җитәкчесен кертеп) артык булса, департамент җитәкчесе урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Департамент җитәкчесенең икенче урынбасары вазыйфасы штат саны 28 берәмлек һәм аннан күбрәк (департамент җитәкчесен кертеп) булганда кертелергә мөмкин.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 40 берәмлектән артык булганда, департамент хезмәткәрләренең штат саны кимендә 16 берәмлек тәшкил итә. Департаментта, әгәр дә департаментның штат саны 16 берәмлектән (департамент җитәкчесен кертеп) артык булса, департамент җитәкчесе урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Департамент җитәкчесенең икенче урынбасары вазыйфасы штат саны 32 берәмлек һәм аннан күбрәк (департамент җитәкчесен кертеп) булганда кертелергә мөмкин.

11. Идарә йә департамент составына керергә, йә мөстәкыйль структур бүлекчә булырга мөмкин. Идарә составында кимендә бер бүлек мәҗбүри булу шарты белән кимендә өч структур бүлекчә булырга тиеш.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 40 берәмлеккә кадәр (40 берәмлекне кертеп) булганда идарә хезмәткәрләренең штат саны кимендә сигез берәмлек тәшкил итә.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 40 берәмлектән артык булганда идарә хезмәткәрләренең штат саны кимендә тугыз берәмлек тәшкил итә. Идарәдә, әгәр дә идарәнең штат саны тугыз берәмлектән артык (идарә башлыгын кертеп) тәшкил итсә, идарә башлыгы урынбасары вазыйфасы каралырга мөмкин. Идарә башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы штат саны 18 берәмлек һәм аннан күбрәк (идарә башлыгын кертеп) булганда кертелергә мөмкин.

12. Бүлек департамент, идарә составына керергә йә мөстәкыйль структур бүлекчә булырга мөмкин. Бүлек секторлардан торырга мөмкин. Сектор департамент, идарә, бүлек составына керергә йә мөстәкыйль структур бүлекчә булырга мөмкин.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 40 берәмлеккә кадәр (40 берәмлекне кертеп) булганда, бүлекләрдә штат саны кимендә өч берәмлек (бүлек башлыгын кертеп) булырга мөмкин. Секторда штат саны ике берәмлек (сектор башлыгын кертеп) булырга тиеш. Сектор башлыгы урынбасары вазыйфасын кертү рөхсәт ителми.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 41 берәмлектән 100 берәмлеккә кадәр булганда, бүлекләрдә штат саны кимендә дүрт берәмлек (бүлек башлыгын кертеп) булырга тиеш, секторда штат саны кимендә ике берәмлек (сектор башлыгын кертеп) булырга тиеш.

Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның штат саны 100 берәмлектән артык булганда, бүлекләрдә штат саны кимендә дүрт берәмлек (бүлек башлыгын кертеп) булырга тиеш, секторда штат саны кимендә ике берәмлек (сектор башлыгын кертеп) булырга тиеш.

Бүлек башлыгы урынбасары вазыйфасы штат саны кимендә алты берәмлек (структур бүлекчә җитәкчесен кертеп) булганда кертелергә мөмкин. Бүлек башлыгының икенче урынбасары вазыйфасы штат саны кимендә тугыз берәмлек (бүлек башлыгын кертеп) булганда кертелергә мөмкин.

13. Хокукый, кадрлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы бүлекләр формасында, мобилизация эше буенча структур бүлекчәләрдә штат саны кимендә өч берәмлек булырга тиеш. Әлеге бүлекчәләрдә штат саны ике берәмлек булган очракта, алар сектор формасында оештырыла.

14. Хокукый, кадрлар белән тәэмин итүне, бухгалтерлык исәбен, мобилизация эшен алып баруны гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр (бүлекләр, секторлар),

аерым белгечләр һәм матбугат сәркатибе дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесенең турыдан-туры буйсынуында булырга тиеш.

15. Дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның хезмәт күрсәтүче персоналы вазыйфалары («машина йөртүче» вазыйфасын кертеп) (балансста булган яки арендага алына торган хезмәт урынында кулланылган автотранспорт булганда) штат расписаниесенә кертелә, яки әлеге персонал функцияләре законнар нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә дәүләт хакимияте башкарма органында үзәк аппаратның хезмәт күрсәтүче персоналының штат санын алга таба кыскартып башка оешмага тапшырыла.